**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 март № 138

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары белән расланган «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары белән расланган «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Кеше эшчәнлегенең төрле тармакларында һәм өлкәләрендә мәгълүмат системалары мәсьәләләрен тикшерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 17 октябрь , 859 нчы;

«Мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү һәм файдалану, инновацияләр һәм «Ачык Хөкүмәт» системасы механизмнарын үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында семинарлар, конференцияләр, форумнар һәм конкурслар үткәрүне оештыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 7 нче;

«Юридик затларга мәгълүмат технологияләрен үстерүгә һәм файдалануга һәм инновацияләр кертүгә бәйле булган чыгымнарын каплауга һәм финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 222 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\138.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 13 март, 138 нче карары редакциясендә)

«Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия (алга таба – Кванториум, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Кванториумның уставында күздә тотылган эшчәнлек төрләрен тормышка ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына (алга таба – баш эш итүче) әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия алу өчен Кванториум баш эш итүчегә түбәндәге документларны кертә:

1) баш эш итүче раслаган форма буенча субсидия алуга заявка (алга таба – заявка);

2) билгеләнгән тәртиптә таныкланган Кванториумны гамәлгә кую документлары күчермәләре;

3) Кванториумның уставында күздә тотылган эшчәнлек төрләрен тормышка ашыруга чыгымнар сметасы;

4) субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1 сенә түбәндәгеләрне раслый торган документлар:

Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмавын;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычлары булмавын;

Кванториумның үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормавын һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавын;

Кванториумның Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алмавын.

5. Субсидия бирү баш эш итүче һәм Кванториум арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Вәкаләтле орган раслаган форма буенча әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны Вәкаләтле органга керткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, аларга ирешү субсидия акчасы исәбеннән тәэмин ителә торган Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, субсидиядән файдалану турында, шулай ук аларга ирешү субсидия акчасы исәбеннән тәэмин ителә торган Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисап кертү тәртибе, вакытлары һәм формалары, субсидияне (субсидиянең калган өлешен) кайтару тәртибе һәм вакытлары, баш эш итүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешү буенча алардан файдалану ихтыяҗы булуы турында карар кабул иткәндә финанслар белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тоткан шарт, баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү хакындагы нигезләмәне үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю күздә тотыла.

6. Баш эш итүче:

теркәлгән документлар белән заявканы алар кертелгән көнне терки;

теркәлгән документлар белән заявканы карап тикшерә һәм аны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында (субсидия бирүдән баш тарту хакында) карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә килешүгә кул куя;

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә кабул ителгән карарның нигезләре күрсәтелә торган хәбәрнамә белән теркәлгән документларны һәм заявканы кире кайтара.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

кертелгән документларның бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

Кванториум тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы;

баш эш итүчегә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

8. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_з + З_{р.м} + З_а + З_с + З_к + З_{п.о} + З_{и.к} + З_к + З_{о.к.о} + З_{пр},$$

монда:
С – бирелә торган субсидия күләме;
$З_з$ – хезмәт өчен түләү фондыннан салымнарны кертеп, хезмәт өчен түләү фондына чыгымнар;
$З_{р.м}$ – белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен чыгым материаллары сатып алуга чыгымнар;
$З_а$ – урыннарны арендалау буенча хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнар;
$З_с$ – элемтә хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;
$З_к$ – хезмәт күрсәтү оешмалары (клининг) хезмәтләренә чыгымнар;
$З_{п.о}$ – оештыру техникасы һәм программа тәэминаты сатып алуга чыгымнар (банклар хезмәтләренә чыгымнарны кертеп);
$З_{и.к}$ – мәгълүмат-консультация хезмәтләренә чыгымнар;
$З_к$ – командировка, вәкиллек чыгымнары;
$З_{о.к.о}$ – төп (мәҗбүри) җиһазлар комплектын сатып алуга, шул исәптән китертүгә һәм кору-көйләү эшләренә чыгымнар;
$З_{пр}$ – башка чыгымнар.

9. Баш эш итүче субсидияне килешүдә билгеләнгән субсидия күчерү графигы нигезендә Кванториумның кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерә:
агымдагы финанс елының беренче кварталы өчен – килешү төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә;
агымдагы финанс елының икенче – дүртенче кварталлары өчен – әлеге Тәртипнең 13 нче пунктында күрсәтелгән хисаплылыкны тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә.

10. Кванториум субсидия күчү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбе алып бара.

11. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия булганда, Кванториумның аны файдалану ихтыяҗы турында карар баш эш итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешү буенча кабул ителә.

Әлеге карар булмаган очракта Кванториум субсидиянең калган өлешен хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарырга тиеш.

12. Баш эш итүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешү буенча әлеге Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән карарны кабул иткән очракта, Кванториум финанслар белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы.

13. Кванториум баш эш итүчегә квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, финанслар белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән аларга ирешү субсидия акчасы исәбеннән тәэмин ителә

торган Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисап тапшыра.

Кванториум баш эш итүчегә хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр хисап елы өчен финанслар белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән аларга ирешү субсидия акчасы исәбеннән тәэмин ителә торган Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисап тапшыра.

14. Баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Кванториумның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

15. Баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланган очракта, Кванториум баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә тиешле акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемен̣ә кире кайтарырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керткән очракта – тулы күләмдә;

субсидиядән файдалану турында, шул исәптән аларга ирешү субсидия акчасы исәбеннән тәэмин ителә торган Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисап кертмәгән очракта – тулы күләмдә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән очракта – Кванториум эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең һәр ирешмәгән мәгънәсе өчен биш процент күләмендә;

субсидия акчасыннан максатка ярашсыз файдалану ачыкланган очракта – субсидиядән максатка ярашсыз файдаланган күләмдә.

16. Әлеге Тәртипнең 11 нче һәм 15 нче пунктларында күрсәтелгән очракларда акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемен̣ә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартканда, алар законнар нигезендә мәҗбүри кайтарылырга тиеш.